**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Бәркәтә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге составына керүче Бәркәтә авылы торак пунктында

**№ 8** **08.11. 2019 ел**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге составына
керүче Бәркәтә авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 8 ноябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2020 елда Бәркәтә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 80 яшьтән һәм аннан өлкәнрәкләрдән, күп балалы аналардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- «Шушма» елгасы аша җәяүлеләр кичү юлын төзүгә, проект һәм эзләнү эшләренә (инженерлык эзләнүләре, проект эшләре, проект экспертизасы);
- Бәркәтә торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Бәркәтә торак пунктында зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (коймаларны урнаштыру, ремонтлау, чүплекләрне урнаштыру, агачларны кисү, коры-сарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, хуҗалык инвентарьларын саклау өчен хуҗалык блогы төзү, керү юлларын, сукмакларны төзекләндерү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документациясе өчен түләү) югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу),

югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнар;

- Бәркәтә торак пунктында су челтәрләрен проектлау (инженерлык эзләнүләре, проект эшләре, проект экспертизасы)
- Бәркәтә торак пунктында йортларның номерлары һәм урам исемнәре язылган табличкалар ясау һәм урнаштыру (ике телдә)

«ӘЙЕ ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 520 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 271 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 271 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге составына керүче Бәркәтә авылында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре-чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2020 елда Бәркәтә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 80 яшьтән һәм аннан өлкәнрәкләрдән, күп балалы аналардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- «Шушма» елгасы аша җәяүлеләр кичү юлын төзүгә, проект һәм эзләнү эшләренә (инженерлык эзләнүләре, проект эшләре, проект экспертизасы);
- Бәркәтә торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Бәркәтә торак пунктында зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (койманы урнаштыру, ремонтлау, чүплекләрне (урна) урнаштыру, агачларны кисү, коры-сарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, хуҗалык инвентарьларын саклау өчен хуҗалык блогы төзү, керү юлларын, сукмакларны төзекләндерү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документациясе өчен түләү) югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнар;
- Бәркәтә торак пунктында су челтәрләрен проектлау (инженерлык эзләнүләре, проект эшләре, проект экспертизасы)

- Бәркәтә торак пунктында йортларның номерлары һәм урам исемнәре язылган табличкалар ясау һәм урнаштыру (ике телдә) - карар кабул ителгән дип таныrга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә :Бәркәтә авылы, Ленин урамы, 76 а йорты. Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет-сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Бәркәтә авыл җирлеге башлыгы: Г.Х.Гайнанова